**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Шәмәк авыл җирлегенең Иске Мәртле авылында гражданнар җыены карары**

18 ноябрь 2025 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Шәмәк авыл җирлегенең Иске Мәртле авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2026 елда Шәмәк авыл җирлегенең Иске Мәртле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Иске Мертле авылында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны ремонтлау)»

3. Җыен нәтиҗәләрен Шәмәк авыл җирлегенең Иске Мәртле авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Шәмәк авыл җирлеге башлыгы _________ И.Н.Никитина

Гражданнар җыены секретаре _________ В.М.Захарова